ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.01.2025 п.г.т.Алексеевское № 27

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 12.09.2019 ел, № 419 «Инфраструктура үсеше бүлегенең муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең республика органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларында үз көчен югалтуын тану хакында» 28.02.2022 № 175 карарына таянып

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 12.09.2019 ел, № 419 «Инфраструктура үсеше бүлегенең муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1-6 нчы кушымталарда – 3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең күпфункцияле үзәкләрендә, читтән торып эшләү урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре».

1.2. 5 нче кушымтада:

2 бүлекнең 2.5 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе;»;

түбәндәге эчтәлекле 3.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«3.1) Граждан хәле актларын рәсмиләштерү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар;»;

9 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) белем һәм (яисә) квалификация турында, гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр турында документлар һәм чит дәүләт территориясендә бирелгән белем алуга бәйле документлар һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе;»;

түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«9.1) хәрби һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белемнең хәрби белем бирү оешмалары тарафыннан бирелә торган белем һәм (яисә) квалификация турында, гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр турында документлар, шулай ук 1992-1995 елларда Россия Федерациясе территориясендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан бирелгән документлар;».

1.3. 6 нчы кушымтада– 2 бүлектәге 2.5 пунктының д пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) хезмәт эшчәнлеге, хезмәт стажы турында документлар (2020 елның 1 гыйнварына кадәрге чорлар өчен);».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтына http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.С. Язынинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**